# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**14.11.2024 ел** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 14 ноябрендә 08.00 сәгатьтә үткәрелгән «2025 елда 1000 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге территориясендә Иске Имән авылында I төркем инвалидлардан; контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

1. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Иске Имән торак пунктында төзелеш материаллары сатып алу һәм зират коймасын урнаштыру буенча эш өчен түләү);
2. Торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Иске Имән торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Иске Имән торак пунктында вак таш япмасын ремонтлау (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдирлау);
3. Электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен,трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау (Иске Имән торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру);
4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Имән торак пунктында ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
5. Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарның вакытлыча туплану урыннарын җыю (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 144 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 96 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 96 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл жирлегенең Иске Имән авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2025 елда 1000 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге территориясендә Иске Имән авылында I төркем инвалидлардан; контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме» дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Иске Имән торак пунктында төзелеш материаллары сатып алу һәм зират коймасын урнаштыру буенча эш өчен түләү);

2. Торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Иске Имән торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Иске Имән торак пунктында вак таш япмасын ремонтлау (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдирлау);

3. Электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен,трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау (Иске Имән торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Имән торак пунктында ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

5. Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарның вакытлыча туплану урыннарын җыю (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);».

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Имән авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче Р.Ә.Исламова